СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**19 октябрь 2020 ел** **№8**

**Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Сәрдәбаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Шушмабаш авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1.Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Сәрдәбаш авылында Сәрдәбаш авылы, Җиңүнең 65 еллыгы урамы, 30 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2020 елның 10 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2.Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Сәрдәбаш авылында Сәрдәбаш авылы, Җиңүнең 65 еллыгы урамы, 30 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2020 елның 10 ноябренә 15 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Җиңүнен 65 еллыгы урамында, Г.Тукай урамының 1-5 нче йортында яшәүчеләр.

2нче этап: Маршал Жуков урамында, Г.Тукай урамының 6-22 нче йортында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Сәрдәбаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 200 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Җиңүнең 65 еллыгы урамының 21нче йортыннан 28 нче йортына кадәр, Г.Тукай урамының 21 нче йортыннан Җиңү 65 еллыгы урамының 30нчы йортына кадәр юлга нигез салу һәм вак таш җәю;

- янгын савыты сатып алу һәм Җиңүнең 65 еллыгы урамы, 21 нче йорт янына урнаштыру?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

5. Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Сәрдәбаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Сәрдәбаш авылы, Җиңүнең 65 еллыгы урамы, 28 йорт, Г.Тукай урамы, 1А йорт адреслары буенча, Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов

СОВЕТ ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН1669012678